КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1739

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан

шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 август, 697 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1018 нче; 2021 ел, 17 май, 341 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1271 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Җир кишәрлекләренең, аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәйсез бәяләүне үткәрү һәм аларны алу, шулай ук автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзүгә, аларны реконструкцияләүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда хокук ияләренә китерелгән зыянны каплау өлешендә җирле үзидарә органнарының автомобиль юллары, метрополитен станцияләре төзү, аларны реконструкцияләү буенча вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин